Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

10 ноябрь, 2025 ел № 5

Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Шәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2019 елның 08 ноябрендәге 59 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 33 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән), карар нигезендә карар чыгарам:

1. Түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Шәле авыл җирлегендә гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Шәле авылында гражданнар җыенын 8 этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2025 елның 25 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Тукай урамындагы 16 йорт янында Урман урамы, Яшьләр урамы, Таулы урамы, Тау асты урамы, Тукай урамының 1 дән 61 йортына кадәр теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

- гражданнар җыенының икенче этабын 2025 елның 25 ноябрендә 12.00 сәгатьтә Таҗиев урамындагы 21а йорт янында Тукай урамының 61А дан 84 йортына кадәр, КамАЗ урамы, Яңа урамы, Таҗиев урамы, Почта урамының 1 дән 32 йортына кадәр теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

- гражданнар җыенының өченче этабын 2025 елның 25 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Тукай урамындагы 110 йорт янында Тукай урамының 85 тән 161 йортына кадәр, Почта урамының 33 дән 65 йортына кадәр, Шәле тыкрыгы урамнарында теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

- гражданнар җыенының дүртенче этабын 2025 елның 25 ноябрендә 16.00 сәгатьтә Кызыл Йолдыз урамындагы 15 йорт янында Кооператив урамы, Кызыл Йолдыз урамының 1 дән 38 йортына кадәр, Һади Такташ урамының 1 дән 41

йортына кадәр, Хәйруллин, Кәвәл урамнарында теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

- гражданнар җыенының бишенче этабын 2025 елның 26 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Һади Такташ урамындагы 58 йорт янында Кызыл Йолдыз урамының 39 дан 84 йортына кадәр, Һади Такташ урамының 42 дән 84 йортына кадәр, Муса Җәлил урамнарында теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

- гражданнар җыенының алтынчы этабын 2025 елның 26 ноябрендә 12.00 сәгатьтә Дуслык урамындагы 27 йорт янында Дуслык, Чокыр урамнарында теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

- гражданнар җыенының җиденче этабын 2025 елның 26 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Ленин урамындагы 26 йорт янында Вахитов урамының 1 дән 37 йортына кадәр, Совет, Ленин урамнарында теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

- гражданнар җыенының сигезенче этабын 2025 елның 26 ноябрендә 16.00 сәгатьтә Казан урамындагы 12 йорт янында Вахитов урамының 38 дән 74 йортына кадәр, Казан, М.Шәйхиева, Г.Сафиуллин, Ф.Сафин, М.Мөхәмәтҗанова, Җиңү, Отрадная, Кыр урамнарында теркәлгән гражданнар өчен уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026 елда Шәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидларны, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларны, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучы мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр түләүдән (үзара салымнан) азат итүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту
- җир асты суларының табигый чыганакларын (чишмәләрне) төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Шәле авыл җирлеге ТатЦИК исемендәге авылда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

Гражданнар җыенын 2025 елның 27 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Совет урамы, 12а йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2026 елда ТатЦИК исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов